АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07.10.2024 № 269

п.г.т.
Алексеевское

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 15.11.2021 ел, № 73 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты Уставы» 2007 елның 08 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар бирде:**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында» Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 73 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәнең 1.2 пунктына «в» пунктын өстәргә, түбәндәге эчтәлекле:

«в) гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле түләүле автомобиль юллары, гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларының түләүле участоклары буйлап транспорт чаралары йөрүне транспорт чарасы йөргән өчен түләү кертү тәртибен үтәү өлешендә гамәлгә ашыруга».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Советының бюджет-финанс мәсьәләләре һәм икътисадый үсеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Сафина Г.Т.).

**Муниципаль район башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С. А. Демидов**